Кояш көлә мин елмаям

Сигезенче март бүген.

Бүген әниләр бәйрәме

Шуңа күңелем шат минем.

***

Әй, әбием, әбекәем,

Кояш кебек син безнең.

Исәнлек бирсен Ходай,

Озын булсын гомерең

***

Бүген әниләр бәйрәме

Бәйрәм белән котлыйбыз.

Матур җырлар җырлыйбыз

Биибез дә, уйныйбыз.

*Резеда Вәлиева*

**Бүген әниләр бәйрәме.**

Нигә бүген бөтен җирдә
Чәчәкләр балкый бездә,
Нигә кояш көлеп карый, -
Беләбез һәммәбез дә.

Бүген әниләр бәйрәме
Бүген җирдә тантана.
Кояш шуңа көлә
Гөлләр шуңа шатлана.